Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советы

КАРАР № 4-1

Балык Бистәсе штп. 2020 елның 2 ноябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнар җыенына әзерлек һәм аны уздыру тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 маддәсе, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ТРЗ номерлы Законының 35 маддәсе һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнар җыенына әзерлек һәм аны уздыру тәртибе турында кушымта итеп бирелә торган Нигезләмәне расларга (алга таба – Нигезләмә).

2. Нигезләмәнең 1.7 пунктындагы 11 абзацны 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык Бистәсе штп., Ленин урамы, 48А йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башлыгы И.Р. Таҗетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Балык Бистәсе шәһәр
җирлеге Советының 2020 елның
2 ноябрендәге 4-1 номерлы
карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы**
**“Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлегендә гражданнар җыенына әзерлек һәм аны уздыру тәртибе турында**
**Нигезләмә**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлегендә гражданнар җыенына әзерлек һәм аны уздыру тәртибе турында әлеге Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 маддәсе, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ТРЗ номерлы Законының 35 маддәсе һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә эшләнде.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Гражданнар җыены гомуми, тигез һәм турыдан-туры ихтыяр белдерү нигезендә үткәрелә.

1.2. Торак пунктның аның территориясендә даими яшәүче яки күбесенчә гомер итүче, тору урыны буенча әлеге торак пунктта теркәлгән һәм сайлау хокукына ия яшәүчеләре гражданнар җыенында катнашырга хокуклы.

1.3. Гражданнарның җыенда катнашуы ихтыяри һәм ирекле.

1.4. Гражданнар җыенда шәхсән катнаша һәм аларның һәркайсы бер тавышка ия.

1.5. Гражданнар җыены җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне турыдан-туры халык тарафыннан хәл итү максатларында үткәрелә.

1.6. Торак пункттагы сайлау хокукына ия яшәүчеләрнең яртысыннан артыгының бер үк вакытта бергә булу (катнашу) мөмкинлеге булмау очрагында гражданнар җыены Уставка ярашлы рәвештә этаплап уздырыла.

## Гражданнар җыенының вәкаләтләре

1.7. Гражданнар җыены түбәндәге мәсьәләләр буенча үткәрелергә мөмкин:

составына күрсәтелгән торак пункт кергән җирлекнең (муниципаль районның) әлеге торак пункт территориясен бүтән җирлек (муниципаль район) территориясенә кертүгә китерүче чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча;

муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә чикләрне үзгәртү, күрсәтелгән җирлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча;

муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләрен гражданнар җыены гамәлгә ашыра торган җирлектә сайлау хокукына ия яшәүчеләрнең саны 100 дән артык булганда, җирлекнең вәкиллекле органын оештыру, аның саны һәм вәкаләтләр срогы мәсьәләсе буенча;

муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турындагы мәсьәлә буенча;

җирлек, шәһәр эчендәге район, федераль әһәмияттәге шәһәрнең шәһәр эчендәге территориясе, муниципаль округ, шәһәр округына керүче яисә муниципаль район чикләрендәге авыллар арасындагы территориядә урнашкан торак пунктта әлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турындагы мәсьәлә буенча;

авыллар арасындагы территориядә урнашкан торак пунктта яңа оешучы җирлек төзү турында халыкның инициативасын күрсәтү максатларында, шулай ук әгәр яңа төзелгән җирлектә сайлау хокукына ия яшәүчеләр саны 300 кешедән артмаганда яңа оешкан җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын тәгаенләү мәсьәләсе буенча;

түбән тыгызлыктагы авыл җирлеге территориясендә яки авыл җирлегендә көн итүчеләр саны 100 кешедән артмаган барып җитү мәшәкатьле (читен) булган урында урнашкан җирлектә аны бетерү мәсьәләсе буенча;

авыл торак пунктында авыл торак пункты старостасына кандидатура тәкъдим итү мәсьәләсе буенча, шулай ук авыл торак пункты старостасының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча;

үзидарәлек хезмәте вазыйфасын биләүгә конкурс үткәргәндә Россия Федерациясе үзидарәлек хезмәте турындагы законда каралган очракларда конкурс комиссиясе составына кандидатуралар күрсәтү максатларында авыл торак пунктында шулай ук гражданнар җыены уздырылырга мөмкин.

муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә инициативалы проектларны тәкъдим итү, әзерләү, сайлап алу һәм тормышка ашыру мәсьәләләре буенча.

**Гражданнар җыенын матди һәм оештыру ягыннан тәэмин итү**

1.8. Гражданнар җыенын уздыру муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан тәэмин ителә.

1.9. Җыенга әзерлек һәм аны уздыру белән бәйле чыгымнар муниципаль берәмлек бюджеты средстволары хисабына башкарыла.

## 2. Гражданнар җыенын чакыру тәртибе

Гражданнар җыенын уздыру инициативасы

2.1. Торак пунктта гражданнар җыенын уздыру инициативасы белән чыга:

- муниципаль берәмлек башлыгы;

- торак пунктның сайлау хокукына ия һәм гражданнар җыенында катнашырга хокуклы кеше саны 10 нан да ким булмаган яшәүчеләре төркеме (ягъни хокуктан файдаланугa сәләтле, торак пункт территориясендә даими яки күбесенчә яшәүче, тору урыны буенча шушы торак пунктта теркәлгән, 18 яшькә җиткән Россия Федерациясе гражданнары, шулай ук торак пункт территориясендә даими яки күбесенчә яшәүче һәм Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре һәм федераль законнар нигезендә җирле үзидарәне гамәлгә ашырганда хокукларга ия чит илләр гражданнары).

2.2.Торак пунктта яшәүчеләрнең инициативасы имза кәгазьләре (подписной лист) (кушымта №1) яки гражданнар җыены уздыру инициативасын тәкъдим итү турында карар кабул ителгән инициаторлар төркеменең җыелыш беркетмәсе рәвешендә рәсмиләштерелергә һәм аларда күрсәтелергә тиеш:

- гражданнар җыенына куела торган мәсьәләләр;

- гражданнар җыенын уздыруның тәкъдим ителә торган сроклары;

- гражданнар җыенын чакыру турындагы инициативаны яклаучы һәр гражданың фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы; паспорты яки аны алыштыручы документының сериясе һәм номеры; аның имзасы һәм имзаны салу датасы.

2.3. Җыен уздыру инициативасын яклау өчен җыйнау зарур булган имзалар саны сайлау хокукына ия, торак пункт территориясендә даими яки күбесенчә яшәүче, тору урыны буенча шушы торак пунктта теркәлгән гражданнар санының 5 процентын тәшкил итә, әмма 10 имзадан да ким була алмый.

2.4. Имза кәгазьләре имза җыюны башкаручы зат тарафыннан раслау датасын, фамилияләрне, исемнәр, аталарының исемнәрен, туу даталарын, паспорт яки аны алыштыручы документларының сериясе һәм номерын, тору урыннарының адресларын күрсәтеп раслана һәм муниципаль берәмлек башлыгына җибәрелә.

### Гражданнар җыенын уздыру турында карар кабул итү тәртибе

2.5. Инициаторлар төркеме (инициатив төркем) тарафыннан чакырылучы гражданнар җыены җирлек Советы карары белән (кушымта №2), ә җирлек Башлыгы инициативасы буенча булганы – җирлек Башлыгы карары белән (кушымта №3) кирәкле барлык документлар килеп ирешкән көннән соң 30 көн эчендә билгеләнә.

2.6. Җирлек башлыгы яки җирлек Советының гражданнар җыенын уздыруны аның максатка ярашлы булмавын сылтау итеп кире кагарга хаклары юк.

2.7. Гражданнар җыенына (гражданнар җыены этапларына) чыгарылган мәсьәлә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килергә тиеш түгел. Гражданнар җыенының соравы (мәсьәләсе) аны күптөрле

аңлатырга мөмкинлек булмаслык итеп тәгъбирләнергә тиеш, ягъни аңа бер генә мәгънәдә җавап бирерлек булсын.

2.8. Гражданнар җыенын тәгаенләү, аны күчерү турында карарны рәсми игълан итү (халыкка җиткерү) тәртибе муниципаль берәмлек уставы (низамнамәсе) белән билгеләнә һәм үзидарәлек хокукый актларын игълан итү (халыкка җиткерү) өчен муниципаль берәмлек уставында каралган тәртиптә игълан ителә (халыкка белдерелә). Җирлек Башлыгы яки җирлек Советының гражданнар җыенын уздыру карарында күрсәтелә: гражданнар җыенына чыгарылучы мәсьәлә; гражданнар җыенын уздыру вакыты һәм урыны турында мәгълүмат; җыенны оештыручы – җирлекнең Башкарма комитеты турында мәгълүматлар.

2.9. Гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрүгә җаваплы булган җирлекнең Башкарма комитеты гражданнар җыены уздыру турындагы җирлек Башлыгы яки җирлек Советы карары нигезендә җирлекнең сайлау хокукына ия яшәүчеләренең исемлеген төзи; гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерли; гаммәви мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән гражданнар җыены турында муниципаль берәмлек халкына хәбәр итә (кушымта №4).

Җирлек Башкарма комитеты гражданнар җыенын уздыру өчен урыннар (биналар) бирергә бурычлы.

2.9.1. Гражданнар җыенын этаплап уздырганда торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү һәм гражданнар җыенын уздыру датасын тәгаенләү территориаль, вакытлы билгеләр буенча мөмкин, шулай ук башка очракларда.

2.9.2.Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү тәртибе гражданнар җыенын тәгаенләү турындагы үзидарәлек (муниципаль) актында күрсәтелә (Кушымта №5, №6).

2.9.3. Торак пунктта яшәүчеләргә алдан ук гражданнар җыенын (гражданнар җыены этапларын) уздыру вакыты һәм урыны хакында хәбәр җиткерелә. Гражданнар җыенын (гражданнар җыены этапларын) тәгаенләү турында карар, гражданнар җыенын (гражданнар җыены этапларын) уздыру вакыты һәм урыны гражданнар җыенын (гражданнар җыены этапларын) уздыру датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча мәҗбүри игълан ителергә (халыкка җиткерелергә) тиешле. Гражданнар җыены этапларын уздыру вакыты һәм урыны гражданнар җыенын билгеләү (тәгаенләү) турындагы бер карарда күрсәтелә.

2.9.4. Гражданнар җыенын этаплап уздыру очрагында җыен этаплап карар кабул ителгән көннән соң бер айдан артмаган срокта уздырыла. Гражданнар җыены этапларын күчерү очрагында җыенны күчерү турында карар җыенны уздыру тәгаенләнгән датага чаклы 10 көннән дә соңга калмыйча закон нигезендә җыен уздырылырга тиешле бер айлык чорны исәпкә алып кабул ителергә тиеш.

2.9.5. Һәрбер гражданнар җыенында катнашучы гражданнар җыены узачак датага хәтле 5 көннән дә соңга калмыйча шушы Нигезләмәнең 2.9 пунктында күрсәтелгәнчә җирлекнең Башкарма комитетында гражданнар җыены хәл итүенә чыгарыла торган материаллар белән танышырга, шулай ук аларның күчермәләрен алырга хокуклы.

2.10. Гражданнар җыены турындагы Нигезләмәгә ярашлы рәвештә гражданнар җыенын уздыру датасы тагы да соңрак срокка күчерелергә мөмкин. Гражданнар җыены датасын күчерү турында карар җыенны уздыру тәгаенләнгән датага чаклы 10 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

## 3. Гражданнар җыенын уздыру тәртибе

3.1. Җыенга килгән гражданнар торак пунктта яшәүчеләр исемлегенә кертелгән сайлау хокукына ия җыенда катнашучы затларны теркәү өчен җирлек Башлыгы вәкаләтләр биргән зат тарафыннан теркәләләр. Исемлектә гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, тору урынының адресы, паспорт сериясе һәм номеры күрсәтелә.

3.2. Җыенга шулай ук җыенда катнашырга теләк белдергән хәлиткеч тавышка хокуксыз башка гражданнар, җыенда тикшерелә торган мәсьәләләр аларның эшчәнлеге бәйле булса, предприятие, учреждение, оешмалар җитәкчеләре, матбугат һәм бүтән гаммәви мәгълүмат чаралары вәкилләре кертелә.

3.3. Торак пунктның сайлау хокукына ия яшәүчеләре исемлегендә төгәлселекләр беленгән очракта торак пунктта яшәүче әлеге җирлек Башлыгы тарафыннан теркәлергә һәм җыенда катнашуга кертелергә мөмкин.

3.4. Язуларның төгәлсезлеген (яки аларның булмавын) раслаучы факт булып граждан шәхесен раслаучы документ (Россия Федерациясе гражданы паспорты, хәрби билет, чит ил гражданы паспорты, вид на жительство (яшәүгә хокук), Россия Федерациясендә вакытлыча яшәүгә рөхсәтнамә һ.б.) булу тора.

3.5. Гражданнар җыены анда торак пунктның сайлау хокукына ия яшәүчеләренең яртысы катнашканда вәкаләтле. Кворум булмаганда гражданнар җыенын уздыруның яңа датасын билгеләү җирлек Башлыгы тарафыннан хәл ителә. Бу очракта гражданнар җыены гражданнар җыенын уздыру билгеләнгән көннән соң ун көннән дә алда үткәрелә алмый.

3.6. Гражданнар җыенын этаплап уздыру очрагында җыенның аерым этапларында гражданнар теләсә никадәрле килгәндә дә барлык үткәрелгән этаплар йомгаклары буенча тавышларны шуннан соңгы санау белән гражданнар җыены вәкаләтле, ягъни җыен үзеннән-үзе бердәм булып кала.

3.7. Гражданнар җыенында тавыш бирү ачык яки яшерен булырга мөмкин. Тавыш бирү рәвеше турында карар гражданнар җыены тарафыннан кабул ителә.

3.8. Яшерен тавыш бирү үткәргәндә гражданнар җыенында катнашу өчен теркәлгән гражданга тавыш бирү өчен бюллетень бирелә (кушымта №7).

3.9. Гражданнар җыенында җирлек Башлыгы яки гражданнар җыенының теркәлгән катнашучылары сaныннан ачык тавыш бирү юлы белән гади күпчелек тавыш белән сайланган бүтән зат рәислек итәргә мөмкин.

3.10. Гражданнар җыены сәркатипне һәм санау комиссиясен сайлый. Санау комиссиясенең әгъзалар саны өч кешедән ким була алмый.

Санау комиссиясе составына рәислек итүче керә алмый.

Санау комиссиясе:

гражданнар җыенына килгән торак пунктта яшәүчеләрнең теркәлүенең дөреслеген, зарурлык булса, аларның гражданнар җыены эшендә катнашуына хокукларын тикшерә;

гражданнар җыены кворумын тәгаенли (гражданнар җыены этапларын уздырудан тыш);

тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирә;

тавышларны саный һәм тавыш бирүнең йомгакларын чыгара (гражданнар җыены этапларын уздырудан тыш);

тавыш бирү йомгаклары турында (гражданнар җыены йомгаклары буенча) беркетмә төзи;

тавыш бирү нәтиҗәләре белән материалларны рәислек итүчегә тапшыра (беркетмә, җыенда катнашучы гражданнарның исемлеге).

3.11. Гражданнар җыенының көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр рәислек итүче, җирлек Башлыгы, гражданнар җыенында катнашуга хокуклы гражданнар тарафыннан кертелергә мөмкин. Көн тәртибенә мәҗбүри тәртиптә гражданнар җыенын чакыру инициаторлары керткән мәсьәләләр кертелә. Күрсәтелгән мәсьәләләр беренче чиратта карала. Гражданнар җыенының көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләрне кертү турындагы карар җыенда булган гражданнарның яртысыннан артыгы аның өчен тавыш биргәндә кабул ителгән булып санала.

3.12. Гражданнар җыенын этаплап уздыру вакытында шулай ук җирлек Башлыгы яки гражданнар җыенының теркәлгән катнашучылары саныннан ачык тавыш бирү юлы белән гади күпчелек тавыш белән сайланган бүтән зат рәислек итәргә мөмкин. Рәислек итүче кандидатурасын җыенда катнашучылар тәкъдим итәргә хаклы.

3.13. Гражданнарның этаплы җыенында тавыш бирү ачык яки ябык (яшерен) булырга мөмкин. Тавыш бирү рәвеше турында карар гражданнар җыены этабында кабул ителә.

3.14. Гражданнар җыенын этаплап уздырганда гражданнар җыенын уздыруның һәрбер этабында санау комиссиясе әгъзалары саныннан гражданнарның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча кворумны һәм йомгак тавышларны санаганда комисиия составында эшләячәк санау комиссиясенең берәр әгъзасы сайлана.

3.15. Гражданнар җыены җыенда рәислек итүче тарафыннан ачыла. Гражданнар җыенында рәислек итүче җыенны уздыруны оештыра, тәртипне саклый, санау комиссиясе эшен яраштыра, тикшерелә торган мәсьәләләр буенча чыгыш ясау өчен сүз бирә, билгеләнгән тавыш бирү тәртибен тәэмин итә.

3.16. Җыенда сәркатип тарафыннан гражданнар җыенын уздыру датасы, вакыты һәм урыны, торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, җыендагылар саны, көн тәртибе, чыгышларның кыскача эчтәлеге, каралучы мәсьәләләр буенча тавыш биргән гражданнар саны күрсәтелгән беркетмә алып барыла (кушымта №8).

3.17. Гражданнар җыенын этаплап уздырганда беркетмәләр җыеннарның һәрбер этабында алып барыла (кушымта №9,№10), кайсыдыр ки шуннан соң барлык үткәрелгән гражданнар җыены этапларының йомгаклары буенча җыенның бер йомгак беркетмәсе рәсмиләштерелә (кушымта №11), шулай ук

Санау комиссиясе беркетмәләре дә (кушымта №12,№13), алар да гражданнар җыенының һәрбер этабындагы тавышларны санау нәтиҗәләре буенча Санау комиссиясенең бер йомгак беркетмәсенә (кушымта №14) рәсмиләштереләләр.

3.18. Гражданнар җыенының йомгак беркетмәсе гражданнар җыены этапларын уздыру датасы, урыны һәм вакыты турындагы мәгълүматларны, көн тәртибен, гражданнарның гомуми саны, җыен этапларында катнашкан гражданнарның гомуми саны турында мәгълүматларны, гражданнар җыены этаплары нәтиҗәләре буенча тавыш бирүнең гомуми нәтиҗәләрен үз эченә ала. Йомгак беркетмә җирлек Башлыгы тарафыннан имзаланучы гражданнар җыены карарын (аны шуннан соңгы рәсми игълан итү (халыкка җиткерү) белән) рәсмиләштерү өчен нигез булып тора.

3.19. Беркетмә җыенда рәислек итүче зат, җыен сәркатибе тарафыннан имзалана һәм җирлек Башлыгына тапшырыла. Беркетмәгә теркәлгән җыенда катнашучыларның исемлеге кушымта итеп теркәлә.

3.20. Санау комиссиясенең гражданнар җыенының уздырылган этаплары йомгаклары буенча йомгак беркетмәсе гражданнар җыены этапларын уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында мәгълүматларны, көн тәртибен, уздырылган җыен этаплары санын, гражданнар җыенының уздырылган этаплары буенча Санау комиссиясенең беркетмәләре санын, җыен үткәрү өчен расланган территориядә яшәүче һәм җыеннар эшендә катнашуга хокуклы гражданнарның гомуми саны, җыен эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны, ЯКЛАП, КАРШЫ бирелгән тавышларның гомуми санын үз эченә ала.

3.21. Йомгак беркетмә Санау комиссиясе рәисе һәм Санау комиссиясе әгъзалары тарафыннан имзалана һәм җирлек Башлыгына тапшырыла.

## 4. Гражданнар җыены карарлары

4.1. Гражданнар җыены карары сайлау хокукына ия җыенда катнашкан гражданнарның яртысыннан артыгы аның өчен тавыш биргәндә кабул ителгән булып санала.

4.2.Җыенда кабул ителгән карарлар үзидарәлек хокукый актлары булып тора, җирлек Башлыгы тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасы үзидарәлек норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш.

4.3.Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең урындагы затлары җирлек низамнамәсе (уставы) белән билгеләнгән алар арасындагы вәкаләтләрне чикләү нигезендә гражданнар җыенында кабул ителгән карарларны үтәүне тәэмин итәләр.

4.4. Җыенда кабул ителгән карар җыенда башка карар кабул итү юлы белән гамәлдән чыгарылырга яки үзгәртелергә яисә суд тәртибендә дөрес түгел дип танылырга мөмкин.

4.5. Гражданнар җыенында кабул ителгән карарлар игълан ителергә (халыкка җиткерелергә) тиеш һәм үзидарәлек хокукый актлары өчен булган таләпләргә ярашлы рәвештә рәсмиләштереләләр.

4.6. Әгәр торак пунктта яшәүчеләрнең турыдан-туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарны тормышка ашыру өчен өстәмә үзидарәлек

хокукый актын кабул итү (чыгару) таләп ителсә, компетенцияләренә күрсәтелгән актны кабул итү (чыгару) кергән җирле үзидарә органы яки җирле үзидарәнең урындагы заты гражданнар җыенында кабул ителгән карар көченә кергән көненнән соң 15 көн эчендә тиешле үзидарәлек актын әзерләү һәм (яки) кабул итү срогын тәгаенләргә тиешләр. Күрсәтелгән срок өч айдан артык була алмый.

**Гражданнар җыены карарларын үтәү**

4.7. Җыенда кабул ителгән карарлар торак пункт территориясендә мәҗбүри үтәлергә тиеш һәм кайсыдыр дәүләт хакимияте органнары, аларның урындагы затлары яки җирле үзидарә органнары тарафыннан аларны раслауның хаҗәте юк.

4.8. Җыенда кабул ителгән карарларны үтәмәү законнар нигезендә җаваплылык китереп чыгара.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлегендә гражданнар җыенына әзерлек һәм аны уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә кушымта №1

# ИМЗА КӘГАЗЕ

Без, түбәндә имза салучылар, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы торак пунктында ____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

(җыенда каралырга мөмкин булган мәсьәләнең тәгъбирләнеше (формулировкасы)) тәгъбирләнешле мәсъәлә буенча ______________________________ гражданнар җыены

(гражданнар җыенын уздыру срогы)

уздыру инициативасын яклыйбыз.

| № № п/п | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туу датасы | Яшәү урынының адресы | Паспорт яки аны алыштыручы документның сериясе, номеры | Имза салу датасы | Имза |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Имза кәгазен таныклыйм ____________________________________________

(имза җыюны башкаручы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме,

_________________________________________________________________

туу датасы, яшәү урыны, паспортының яки аны алыштыручы документының сериясе һәм номеры)

_________________________________________________________________

_____________________ (имза һәм дата)

**Гражданнар җыены инициаторлар төркеме инициативасы буенча чакырылу очрагында**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлегендә гражданнар җыенына әзерлек һәм аны уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә кушымта №2

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советы

**КАРАР**

Балык Бистәсе штп. № ____

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлегендә гражданнар җыенын билгеләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ТРЗ номерлы Законының 35 маддәсе һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлегендә үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 20 __ елның ___ ____________-дә ___ сәг. 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

“Сез 20__ елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге территориясендә тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, *(үзара салымнан азат ителүче гражданнар категориясен күрсәтергә)* гайре, ___ сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы?” *(планлаштырылган эшләр санап кителә):*

“ЯКЛЫЙМ” “КАРШЫ”

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән алып 3 көн эчендә шәһәр җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карар игълан ителгән (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

Балык Бистәсе муниципаль районы
Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башлыгы И.Р. Таҗетдинов

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлегендә гражданнар җыенына әзерлек һәм аны уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә кушымта №3

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Глава Рыбно-Слободского городского поселения**
**Рыбно-Слободского муниципального района**
Ленина ул., д.48"а",
пгт. Рыбная Слобода, 422650

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башлыгы**
Ленин урамы, 48 "а"нче йорт,
Балык Бистәсе, 422650

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20___ елның ___ ______________ ___________ № _____

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ТРЗ номерлы Законының 35 маддәсе һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 20__ елның ___ __________-нә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына куела торган сорауны расларга: “Сез 20__ елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы ____________ авыл җирлегенең ____________ авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, __________________________________________________ гайре, ___ __ сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы?” *(планлаштырылган эшләр санап кителә):*

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

“ЯКЛЫЙМ” “КАРШЫ”

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 3 көн эчендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык Бистәсе штп., Ленин урамы, 48А йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карар игълан ителгән (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башлыгы И.Р. Таҗетдинов

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлегендә гражданнар җыенына әзерлек һәм аны уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә кушымта №4

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы ___________ авыл җирлегенең
____________________торак пунктында сайлау хокукына ия яшәүчеләрнең
(торак пунктның исеме)

ИСЕМЛЕГЕ

“___” ________________, 20___ ел

| №№ пп | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туган елы (18 яшь булса, туу датасының числосы, ае) | Яшәү урынының адресы | Паспорт сериясе, номеры | Имза |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

Гражданнар җыенында рәислек итүче __________ ________________________
